МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.04.2017 г. Казань № 337од

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә булган Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше торышын дәүләти контрольдә тоту буенча Административ егламентны раслау турында

2008 елның 26 декабрендә кабул ителгән “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне башкарган вакытта юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында”гы 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 31 декабрендә кабул ителгән 1192 нче “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарама органнары тарафыннан дәүләт функцияләрен үтәүнең Административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында”гы карары белән боерам:

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә булган Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше торышын дәүләти контрольдә тоту буенча Административ регламентны расларга (кителелә).
2. Музей эшен үстерү бүлегенә (Д.Д.Натфуллин) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәүне тәэмин итәргә.
3. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгының
________________№_____
боерыгы белән
расланган

**Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә булган Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше торышын дәүләти контрольдә тоту буенча Административ регламент**

## 1. ГОМУМ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Бу Регламент Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының (алга таба - Министрлык) Татарстан Республикасы территориясендә булган Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше торышын дәүләти контрольдә тоткан вакыттагы (алга таба – дәүләт контроле) гамәлләрнең вакытын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт функцияләренең төре: булган Россия Федерациясе Музей фондының Татарстан Республикасы территориясендәге дәүләт өлеше торышын дәүләти контрольдә тоту.

1.3. Дәүләт функциясен үтәүче булып Министрлык санала.

Дәүләт функциясен Министрлыкның Музей эшен үстерү бүлеге (алга таба - Бүлек) башкара.

Дәүләт функциясе Министрлыкның Татарстан Республикасы мәдәният министры (алга таба - министр), Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары (алга таба - министр урынбасары) имзалаган боерык белән тикшерү үткәрергә вәкаләте булган вазифаи затлар (алга таба - вазифаи затлар) тарафыннан башкарыла.

2008 елның 26 декбрендә кабул ителгән “Дәүләт контроле (күзәтүе) һәм муниципаль контроль башкарган вакытта юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында”гы 294-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 маддәсе һәм Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2015 елның 28 апрелендә кабул ителгән “Бердәм тикшерүләр реестры формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында”гы 415 нче карар (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 415 нче карары) нигезендә тикшерүләрнең бердәм реестрына тиешле мәгълүматны кертү Министрлыкның вәкаләтле вазифаи заты тарафыннан башкарыла.

Дәүләт функцияләрен башкарган вакытта Министрлыкның вазифаи затлары прокуратура органнары, экспертлар һәм эксперт оешмалар, дәүләт хакимияте органнары тикшерү объекты белән хезмәттәшлек итә.

1.4. Дәүләт функциясе түбәндәгеләр нигезендә башкарыла:

Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турындагы кодексы (алга таба – КоАП РФ), (Россия Федерациясе Законнары җыелмасы 2002, № 1, 1 нче бит, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

1992 елның 9 октябрендә кабул ителгән № 3612-1 Россия Федерациясе Законнары нигезләре (Ведомости Съезда народных депутатов Российской Федерации и Верховного Совета Российской Федерации, 1992, № 46, 2615 бит, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

Россия Федерациясенең 1993 елның 15 апрелендә кабул ителгән "Мәдәни мирасны чыгару һәм кертү турында"гы № 4804-1 законы (Ведомости Съезда народных депутатов Российской Федерации и Верховного Совета Российской Федерации, 1993, № 20, 718 бит, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

1996 елның 26 маенда кабул ителгән "Россия Федерациясенең музей фонды һәм Россия Федерациясендә музейлар турында"гы № 54-ФЗ Федераль законы (алга таба – Федераль закон № 54-ФЗ) (Россия Федерациясе Законнары җыелмасы, 1996, № 22, 2591 бит, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

2006 елның 2 маенда кабул ителгән "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында"гы № 59-ФЗ Федераль законы (Россия Федерациясе Законнары җыелмасы, 2006, № 19, 2060 бит, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

2008 елның 26 декабрендә кабул ителгән "Дәүләт контролен (күзәтү) һәм муниципаль контроль үткәргән вакытта юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында"гы № 294-ФЗ (алга таба - № 294-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнары җыелмасы, 2008, № 52, 6249 бит, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1998 елның 12 февралендә кабул ителгән "Россия Федерациясе Музей фонды, Россия Федерациясе музей фондының Дәүләт каталогы, Россия Федерациясендә музейлар эшчәнлеген лицензияләү турында"гы 179 нчы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең № 179 карары) (Россия Федерациясе Законнары җыелмасы, 1998, № 8, 949 бит, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 30 июнендә кабул ителгән "Дәүләт контроль (күзәтү) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләрне планлы тикшерү үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында"гы 489 нчы карары (Россия Федерациясе Законнары җыелмасы, 2010, № 28, 3706 бит, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

Россия Федерациясенең 2015 елның 28 апрелендә кабул ителгән "Бердәм тикшерүләр реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында"гы 415 нче карары (Россия Федерациясе Законнары җыелмасы, 2015, № 19, 2825 бит);

Россия Федерациясенең статистика буенча дәүләт комитетының 2004 елның 23 гыйнварында кабул ителгән "Россия Финанс министрлыгы карамагындагы Гохран оешмалары өчен музейлар предметларында кыйммәтле металлар һәм кыйммәтле ташлар булуны статистик күзәтү өчен статистик инструментарийларны раслау турында"гы 6 нчы карары (алга таба – РФ Госкомстат карары № 6);

Россия Федерациясе Мәдәният һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгының 2007 елның 22 ноябрендә кабул ителгән "Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының Россия Федерациясе Музей фондының Дәүләт каталогын алып бару буенча дәүләт функциясен үтәү Административ регламентын раслау турында"гы 1320 нче боерыгы (алга таба – Мәдәният министрлыгының №

1320 боерыгы) (Башкарма хакимиятнең федераль органнары норматив актлары бюллетене, 2008, № 30, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендә кабул ителгән “Дәүләт контролен (күзәтү) һәм муниципаль контрольне башкарган вакытта юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында”гы Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру турында”гы 141 нче боерык (алга таба – Россия Икътисади үсеш министрлыгының № 141 боерыгы) (Российская газета, 2009, № 85, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

Федераль дәүләт статистика хезмәтенең 2016 елның 7 декабрендә кабул ителгән “Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы оешмалары өчен мәдәният оешмалары эшчәнлеген статистик күзәтү өчен статистик инструментарийларны раслау турында”гы 764 нче боерыгы (алга таба – Росстат боерыгы № 764);

Татарстан Республикасының 1998 елның 3 июлендә кабул ителгән “Мәдәният турында”гы № 1705 законы (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 1998, № 7, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

Татарстан Республикасының 2010 елның 14 октябрендә кабул ителгән “Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында”гы № 69-ЗРТ законы (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2010, № 10, 1203 бит, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

Татарстан Республикасының 2003 елның 12 маенда кабул ителгән “Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында”гы № 16-ЗРТзаконы (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2014, № 7, 685 бит, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 18 августында кабул ителгән “Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре” (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыелмасы” журналы, 2005, № 33-34, 0772 бит, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып).

1.5. Дәүләт контроле объектлары булып Татарстан Республикасы территориясендә булган һәм Россия Федерациясе Музей фондының федераль милектә яки Татарстан Республикасы милкендә булган дәүләт өлеше составына кертелгән, шулай ук № 54-ФЗ Федераль закон үз көченә кергәннән соң дәүләт музейлары, башка дәүләт учреждениеләре тарафыннан гамәлгә куючылар акчаларына яки үз һәм башка акчаларга сатып алынган һәм оператив идарәгә беркетелгән яки аларга файдалануга бирелгән музей предметлары һәм музей коллекцияләре санала (алга таба – тикшерү объекты).

1.6. Дәүләт  контроле объекты булып тикшерү объектының музей предметлары һәм музей коллекцияләренең сакланышын һәм саклау шартларын тәэмин итү өлкәсендә расланган федераль һәм Татарстан Республикасы законнары мәҗбүри таләпләрен үтәү санала.

1.7. Бу Регламентта файдалана торган төшенчәләр № 294-ФЗ Федераль законы, Россия Федерациясенең Музейлар һәм музей эше өлкәсендәге законнар белән билгеләнгән аңлатмаларда кулланыла.

Министрлык вазифаи затларының дәүләт контролен башкарган вакыттагы хокуклары һәм бурычлары

1.8. Министрлыкның вазифаи затлары дәүләт контролен башкарган вакытта түбәндәгеләргә хокуклы:

а) башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яки ведомство дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалардан Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән исемлеккә кертелгән документ һәм мәгълүматларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында түләүсез соратып ала;

б) Россия Федерациясенең мәгълүматны саклау турындагы закон таләпләрен истә тотып, үз компетенцияләре кысаларында тикшерелә торган объектның автоматлаштырылган мәгълүмат системалары мәгълүмат базалары һәм банкына керү мөмкинлеген алу;

в) тикшерергә тиешле тикшерү объекты (алга таба – тикшерү объекты, тикшерелә торган зат) җитәкчесе, башка вазифаи зат яки вәкаләтле вәкилдән тикшерү предметына кагылышлы документлар алу, аларны карау, кирәк булган очракта аларның күчермәләрен алырга;

г) тикшерү өчен кирәкле техник чаралардан, шул исәптән исәпләү приборлары, компьютерлар, күчермә алу аппаратлары, сканер, телефон (шул исәптән кесә телефоннары), аудио-видеоязма чаралары, фотоаппартлардан файдалану, аларны тикшерү объекты бинасына (аның филиалына) алып керү, аудиоязма, фото- һәм видеога төшерергә;

д) тикшерү объектыннан музей предметларының махсус исәбе һәм музей коллекцияләренең документларын һәм дәүләт контролен башкару өчен кирәкле мәгълүмат, шул исәптән электрон документлар формасында, соратып алу һәм алар белән танышу;

е) тикшерү үткәрү турныдагы боерыкта күрсәтелгән контроль буенча чаралар исемлеге белән билгеләнгән күләмдә музей предметларын һәм музей коллекцияләрен тикшерү;

ж) музей предметларында махсус исәп кагыйдәләре (инструкцияләре) буенча куелган маркировка яки башка идентификация билгеләре булуны тикшерү;

з) тикшерү объектыннан дәүләт контролен башкару өчен әһәмиятле саналган хәлләр турында мәгълүмат алу, шул исәптән язма формада;

и) дәүләт контролен үткәргән вакытта туган сорауларны ачыклау таләп ителгән очракта музей предметлары һәм музей коллекцияләренә, исәп документларына карата экспертиза билгеләү;

1.9. Министрлыкның вазифаи затлары дәүләт контролен башкарган вакытта түбәндәгеләрне эшләргә тиеш:

а) Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелгән мәҗбүри таләпләрне кисәтү, ачыклау һәм чик кую буенча вәкаләтләрне вакытында һәм тулысынча үтәргә;

б) Россия Федерациясе законнарын, тикшерү объектының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;

в) министрның (министр урынбасары) аны үткәрү турындагы боерыгы нигезендә тикшерү үткәрергә;

г) тикшерүне хезмәт вазифаларын башкарган вакытта гына, күчмә тикшерүне – эш таныклыгы, министр (министр урынбасары) боергының күчермәсе булган очракта гына үткәрергә. Планнан тыш тикшерү үткәргән вакытта тикшерү объектының эшчәнлеген башкару урыны буенча урнашкан прокуратура органы белән тикшерү үткәрүне килештерү турындагы документ күчермәсен күрсәтергә тиеш;

д) тикшерү объектының җитәкчесе, башка вазифаи зат яки вәкаләтле вәкиленә тикшерү үткәргән вакытта катнашырга һәм тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча аңлатма бирүгә каршы төшмәскә;

е) тикшерү үткәргән вакытта катнашкан тикшерү объекты җитәкчесе, башка вазифаи зат яки вәкаләтле вәкилгә тикшерү предметына кагылышлы мәгълүмат һәм документларны бирергә;

ж) тикшерү объектының җитәкчесе, башка вазифаи зат яки вәкаләтле вәкилне тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыру;

з) тикшерү объектының җитәкчесе, башка вазифаи зат яки вәкаләтле вәкилне ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яки) мәгълүмат белән таныштыру;

и) ачыкланган кагыйдә бозулар факты буенча чара күргән вакытта аларның Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметлары һәм музей коллекцияләре өчен потенциаль куркынычын исәпкә алу, шулай ук гражданнарның, шул исәптән шәхси эшмәкәрләр, юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен чикләүгә юл куймаска;

к) тикшерелгән зат шикаять биргән вакытта Россия Федерациясе законнары нигезендә расланган тәртиптә үз гамәлләреңнең нигезлелеген расларга;

л) № 294-ФЗ Федераль законы белән расланган тикшерү үткәрү вакытын үтәргә;

м) тикшерү объектыннан Россия Федерациясе законнарында күрсәтү каралмаган документлар һәм башка мәгълүматларны таләп итмәскә;

н) тикшерү объектының җитәкчесе, башка вазифаи зат яки вәкаләтле вәкил үтенече буенча күчмә утырыш үткәрер алдыннан аларны бу Регламентның нигезләмәләре белән таныштырырга;

о) тикшерә торган затта исәп журналы булган очракта, аңа күчмә утырыш үткәрү турында язып калдырырга;

п) инвалидлар һәм физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне министрлыкның вазифаи затлары, тикшерү үткәрү өчен вәкаләтлеләр белән очраштырырга;

1.10. Дәүләт контролен башкарган вакытта Министрлыкның вазифаи затларының түбәндәгеләргә хокукы юк:

а) Министрлык вәкаләтләренә кагылышлы булмаган мәҗбүри таләпләрне үтәүне тикшерергә;

б) СССР һәм РСФСР башкарма хакимият органнары норматив хокукый актлары белән расланган һәм Россия Федерациясе законнарына туры килмәгән таләпләрне үтәүне тикшерергә (әлеге абзац таләпләре 2017 елның 30 июненә кадәр гамәлдә);

в) СССР һәм РСФСР башкарма хакимият органнары норматив хокукый актлары белән расланган таләпләрне, шулай ук куллану бурычы Россия Федерациясе законнарында каралмаган норматив документлар таләпләрен үтәүне тикшерергә (әлеге абзац таләпләре 2017 елның 1 июленә кадәр гамәлдә);

г) мәҗбүри таләпләр һәм муниципаль хокукый актлар белән расланган, Россия Федерациясе законнары белән расланган тәртиптә нәшер ителмәгән таләпләр үтәлешен тикшерергә;

д) аны үткәргән вакытта тикшерү объектының җитәкчесе, башка вазифаи зат яки вәкаләтле вәкил булмаган очракта планлы һәм планнан тыш күчмә тикшерү үткәрергә, андый тикшерүне Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметлары һәм музей коллекцияләренә зыян китерү сәбәпле үткәрелгән тикшерү искәрмә булып тора.

е) әгәр дә тикшерү объекты булмаган һәм тикшерү предметына кагылышы булмаган очракта документлар, мәгълүмат, продукция үрнәкләре, әйләнә-тирә мохит объектын тикшерү һәм җитештерү мохиты объектлары пробасын тәкъдим итүне таләп итәргә, шулай ук андый документларның төп нөсхәләрен алырга;

ж) күрсәтелгән үрнәкләрне алу турындагы беркетмәне тутырмыйча аларны тикшерү, сынау, үлчәү өчен продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектларын тикшерү һәм җитештерү мохиты объектлары пробасын алырга;

з) тикшерү үткәрү нәтиҗәсендә алынган һәм дәүләт, коммерция, эш, башка закон белән саклана торган мәгълүматны һәм серне таратырга, Россия Федерациясе законы белән каралган очраклар искәрмә булып тора;

и) расланган тикшерү үткәрү вакытын арттырырга;

к) тикшерү объектына алар хисабына контроль үткәрү буенча чаралар турында кисәтү һәм тәкъдимнәр бирүне башкарырга;

л) тикшерү объектыннан башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яки дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары карамагындагы органнарында булган, Россия Федерациясе хөкүмәте билгеләгән исемлеккә кертелгән документлар һәм (яки) мәгълүмат, шул исәптән рөхсәт бирү документларын таләп итәргә;

м) тикшерү объектыннан тикшерүне башлаганчы документлар, мәгълүмат таләп итәргә. Тикшерү үткәрү турындагы карар һәм боерыктан соң ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында кирәкле документлар һәм (яки) мәгълүматны соратып алырга хокуклы.

Дәүләт контроле буенча чаралар үткәрелүче затларга карата хокуклар һәм бурычлар

1.11. Тикшерү объектының җитәкчесе, башка вазифаи зат яки вәкаләтле вәкил тикшерү үткәргән вакытта түбәндәгеләргә хокуклы:

а) тикшерү үткәргән вакытта үзе катнашырга, тикшерү предметына кагылышлы сораулар туган очракта аңлатмалар бирергә;

б) Министрлыктан, Министрлыкның вазифаи затларыннан тикшерү предметына кагылышлы һәм аны тәкъдим итү № 294-ФЗ Федераль закон белән каралган мәгълүматны алырга;

в) Министрлык тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яки дәүләт

органнары яки җирле үзидарә органнары карамагында булган органнарыннан алынган доументлар һәм (яки) мәгълүмат белән танышырга;

г) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соралган документ һәм (яки) мәгълүматны Министрлыкка шәхси инициативалары буенча тәкъдим итәргә;

д) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында тикшерү нәтиҗәләре белән танышу турында, алар белән, шулай ук Министрлыкның вазифаи затларының кайбер гамәлләре белән килешү-килешмәүне күрсәтергә;

е) Министрлыкның вазифаи затларының гамәлләренә (ваемсызлыгы) карата административ һәм (яки) суд тәртибендә Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять бирергә;

ж) Россия Федерациясе Президенты карамагындагы эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча Вәкаләтле яки Татарстан Республикасы карамагындагы эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча Вәкаләтлене тикшерүдә катнашырга җәлеп итәргә.

1.12. Тикшерү объектлары тикшерү үткәргән вакытта түбәндәгеләрне эшләргә тиеш:

а) Министрлыкның күчмә тикшерүне үткәрүче вазифаи затларына күчмә тикшерүгә кадәр документлар тикшерелмәгән очракта, күчмә тикшерүнең максаты, бурычлары һәм предметына бәйле документлар белән танышу мөмкинлеген бирү, шулай ук мәдәни мирас объектлары урнашкан территориягә Министрлыкның вазифаи затларын, тикшерүдә катнашучы экспертларны, эксперт оешмалары вәкилләрен кертүне тәэмин итү;

б) мәҗбүри бурычларны үтәү буенча чараларны оештырган һәм үткәргән өчен җаваплы тикшерү объектының җитәкчеләре, башка вазифаи затлар яки вәкаләтле вәкилләрнең катнашуын тәэмин итү;

в) нигезләнгән запрос алынган очракта ун көн эчендә Министрлыкка запростагы документларны җибәрергә.

1.13. Дәүләт функциясен үтәү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр санала:

1) бу Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән, ике нөсхәдә тутырылган тикшерү акты;

2) тикшерүләрне теркәү журналында (булган очракта) күчмә тикшерү үткәрү турындагы язу (тикшерүләрне теркәү журналы формасы Россия Икътисади үсеш министрлыгының 141 нче боерыгы белән расланган);

3) № 294-ФЗ Федераль законның 13.3 маддәсе һәм РФ Хөкүмәтенең 415 нче карары нигезендә тикшерүләрнең бердәм реестрына кертелгән тиешле мәгълүмат;

мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланганда:

4) тикшерү актына кушымта саналган һәм бу Регламентның 2 нче кушымтасы нигезендә тутырылган мәҗбүри таләпләрне бозуга чик кую турындагы күрсәтмә (алга таба - күрсәтмә);

5) РФ Административ хокук бозулар кодексында каралган һәм бу Регламентның 3 нче кушымтасы нигезендә тутырылган административ хокук бозу турындагы беркетмә;

Ачыкланган хокук бозуларда җинаять составы билгеләре булмаган очракта:

6) хокук органнарына гаепле затларны җаваплылыкка тарту турында карар кабул итү өчен җибәрелгән гариза һәм тикшерү материаллары.

Дәүләт функциясен үтәү өчен нигез булып Министрлыкка гражданнардан, оешмалардан алынган мөрәҗәгать, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан (алга таба – гариза бирүче) алынган мәгълүмат саналса, дәүләт функциясен үтәү нәтиҗәсе буенча гариза бирүчегә тиешле тәртиптә җавап җибәрелә.

## 2. ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮ ТӘРТИБЕНӘ ТАЛӘПЛӘР

Дәүләт функциясен үтәү турында мәгълүмат бирү тәртибе

2.1. Министрлыкның урнашкан урыны һәм Министрлыкка дәүләт функциясен үтәү мәсьәләләре буенча документлар һәм мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен почта адресы: 420015, Казан шәһәре, Пушкин урамы, 66/33 йорт.

2.2. Министрлыкның эш вакыты: шимбә һәм якшәмбедән кала, көн саен, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00дән 18.00гә, җомга 9.00дән 16.45кә кадәр, төшке аш вакыты 12.00дән 13.00кә кадәр. Бәйрәм алды көннәрендә эш көне бер сәгатькә кыскара.

Министрлыкка пропуск һәм (яки) шәхесне раслаучы документ (паспорт, шәхесне раслаучы башка документ, Россия Федерациясе законы нигезендә) буенча керергә була.

2.3. Министрлыкның белешмә өчен телефоннары:

Министрның дәүләт функциясен үтәү мәсьәләсенә кураторлык итүче урынбасарының кабул итү бүлмәсе: 8 (843) 264-74-11;

Белешмә һәм консультация өчен телефоннар: 8 (843) 264-75-13 – Министрлыкның музей эшен үстерү бүлеге.

2.4. Министрлыкның рәсми сайты: www.mincult.tatarstan.ru.

2.5. Министрлыкка электрон мөрәҗәгатьләр юллау өчен электрон почта адресы: mkrt@tatar.ru.

2.6. Дәүләт функциясен үтәү буенча мәгълүмат, шул исәптән аны үтәү барышы турында, Министрлыкка шалтыратып, Бүлек белгечләренә шәхси мөрәҗәгать итеп, почта аша Министрлыкка хат юллап, Министрлыкның рәсми сайты, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы (www.gosuslugi.ru), Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (www.uslugi.tatarstan.ru) аша электрон рәвештә алынырга мөмкин.

2.7. Министрлыкның рәсми сайтында (www.mincult.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (www.uslugi.tatarstan.ru), Министрлык бинасында мәгълүмати стендта дәүләт функциясен үтәү буенча түбәндәге мәгълүмат урнаштырыла:

- Министрлыкның урнашкан урыны турындагы мәгълүмат, эш графигы, телефон һәм факс номерлары, дәүләт функциясен үтәү тәртибе турындагы мәгълүмат бирә алган вазифаи затларның электрон почтасы адресы;
- ел саен раслана торган хокук бозуларны кисәтү программасы;
- норматив хокукый актлар һәм аларның аерым өлешләре исемлеге, аларда үтәү шарты дәүләт контроле предметы саналган мәҗбүри таләпләр булырга тиеш;
- мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча мәгълүмат, шул исәптән бастырылган мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча ярдәмлекләрдә, семинар һәм конференцияләр

үткәрү, массакүләм мәгълүмат чараларында аңлату эшләре алып бару. Мәҗбүри таләпләр үзгәргән очракта мәҗбүри таләпләр кертүче яңа норматив хокукый актлар булу турында комментарийлар урнаштырыла;

- даими, елга бер тапкырдан да кимрәк башкарылмаган төбәк дәүләт күзәтүен башкару тәҗрибәсен гомумиләштерү буенча мәгълүмат, шул исәптән мәҗбүри таләпләрне бозуның аеруча күп очрый торган очракларын күрсәтеп;

- дәүләт функциясен үтәү тәртибе турындагы мәгълүмат (бу Регламент – Министрлык сайтында, бу Регламенттан өземтәләр - мәгълүмати стендта);

- планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы (алга таба – еллык тикшерүләр планы);

- дәүләт функциясен үтәгән вакытта башкарылган гамәлләр (ваемсызлык) һәм карарларга карата шикаять бирү тәртибе;

- дәүләт функциясен башкарган вакытта гамәлләрнең эзлеклелеген чагылдыручы блок-схема.

Дәүләт функциясен үтәү буенча мәгълүмат үзгәргән очракта ул яңартыла.

2.8. Телдән мөрәҗәгатькә шунда ук җавап бирелә, язма һәм (яки) электрон почта аша алынган мөрәҗәгатькә җавап, күрсәтелгән почта адресы буенча яки электрон адреска мөрәҗәгать Министрлыкта теркәлгәннән соң утыз көн эчендә җибәрелә. Анда куелган сорауларга җавап, башкаручының исем-фамилиясе һәм телефон номеры күрсәтелергә тиеш. Җавап дәүләт функциясе үтәлеше өчен җавап бирүче министр урынбасары тарафыннан имзалана.

Министрлыкның шалтыратуны кабул иткән вазифаи заты куелган сорауларга җавап бирә алмаган очракта, телефон шалтыратуы башка вазифаи затка күчерелергә яки мөрәҗәгать итүчегә тиешле мәгълүмат алырлык телефон номеры әйтелергә тиеш.

### Дәүләт контроле буенча чаралар үткәргән өчен юридик затлардан акча алуга юл куелырга тиеш түгел

2.9. Тикшерелә торган затлардан дәүләт контроле буенча чаралар үткәргән өчен акча алынмый, шул исәптән тикшерүгә җәлеп ителгән экспертлар һәм эксперт оешмалары хезмәте өчен дә.

### Дәүләт функциясен үтәү вакыты

2.10. Тикшерүләрнең һәркайсын үткәрү вакыты (документларны (планлы һәм планнан тыш), шулай ук күчмә (планлы һәм планнан тыш) егерме эш көненнән арта алмый.)

2.11. Министрлыкның вазифаи затларының нигезле тәкъдимнәре буенча катлаулы һәм (яки) озак дәвам иткән тикшеренүләр, сынаулар, махсус экспертизалар һәм эзләнүләр үткәрергә туры килгән очракта, күчмә планлы тикшерү үткәрү вакыты министр тарафыннан озайтылырга мөмкин, әмма ун эш көненнән дә озакка түгел. Тикшерү үткәрүне кабат туктатуга юл куелмый.

2.12.Юридик затларны планлы тикшерүләр өч елга бер тапкырдан да артыграк үткәрелми.

Планлы тикшерүләр үткәрү өчен сәбәпләр

2.13. Планлы тикшерүләр Министрлык тарафыннан эшләнгән һәм расланган еллык тикшерүләр планы буенча, министр (министр урынбасары) боерыгы нигезендә үткәрелә.

Еллык тикшерүләр планы Министрлык тарафыннан эшләнә һәм № 294-ФЗ Федераль закон нигезендә прокуратура органнары белән килештерелә.

2.14. Планлы тикшерүне еллык тикшерүләр планына кертү өчен сәбәп булып:

1) тикшерү объекты дәүләт тарафыннан теркәлүгә;

2) тикшерү үткәннән соң икенче тикшерүгә 3 елдан соң тикшерелергә тиеш.

2.15. Расланган еллык планнар кызыксынган кешеләр игътибарына Министрлыкның рәсми сайты аша яки башка юл белән җиткерелә.

Планнан тыш тикшерүләр үткәрү өчен сәбәпләр

2.17. Планнан тыш тикшерүләр үткәрү өчен сәбәп булып түбәндәгеләр санала:

1) тикшерү объектының ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуны бетерү турындагы күрсәтмәне үтәү вакыты тәмамлану;

2) Министрлык вазифаи затының Министрлыкка алынган гражданнар, шул исәптән шәхси эшмәкәрләр, юридик затлардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чараларыннан түбәндәге очраклар буенча башлангыч тикшерү нәтиҗәләре буенча нигезле күрсәтмәсе:

а) Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметлары һәм музей коллекцияләренә зыян килү куркынычы туу;

б) Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметлары һәм музей коллекцияләренә зыян салу;

в) кулланучылар хокукларын бозу;

3) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләре буенча һәм прокурорның прокуратура органнарына алынган материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнар үтәлешен күзәтү кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы таләбе нигезендә дөнья күргән министр боерыгы.

2.18. Министрлыкка мөрәҗәгать иткән кешенең шәхесен расларга мөмкинлек бирми торган мөрәҗәгать һәм гаризалар, шуай ук бу Регламентның 2.17 пунктының 2 нче ярдәмче пунктында күрсәтелгән фактлар турындагы мәгълүмат булмаган мөрәҗәгать һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез була алмый. Мөрәҗәгать һәм гаризада күрсәтелгән мәгълүмат бу Регламентның 2.17 пунктының 2 нче ярдәмче пункты нигезендә планнан тыш тикшерү өчен нигез булган очракта, Министрлыкның вазифаи заты мөрәҗәгать һәм гаризаның авторлыгына шик туса, мөрәҗәгать иткән кешене ачыклау өчен чара күрергә тиеш. Гариза бирүче тарафыннан электрон документлар рәвешендә тапшырылган мөрәҗәгать һәм гариза бердәм идентификация һәм аутентификация системасында мәҗбүри теркәлүне күздә тоткан мәгълүмати-коммуникацион технологияләрдән файдаланып җибәрелгән очракта гына планнан тыш тикшерү өчен нигез булып тора ала.

2.19. Мөрәҗәгать һәм гаризалар, бу Регламентның 2.7 пунктының 2 нче ярдәмче пунктындагы фактлар турындагы мәгълүматны караган вакытта, алданрак алынган шуңа охшаш мөрәҗәгать һәм гариза, мәгълүматны карау, шулай ук тиешле юридик затларга карата контроль буенча үткәрелгән чараларның нәтиҗәләре истә тотылырга тиеш.

2.20. Мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куйган зат турында дөрес мәгълүмат, бу Регламентның 2.17 пунктының 2 нче ярдәмче пунктында күрсәтелгән фактлар турында җитәрлек мәгълүмат булмаган очракта, Министрлыкның вәкаләтле вазифаи затлары тарафыннан алынган мәгълүматны башлангыч тикшерү үткәрелергә мөмкин. Башлангыч тикшерү үткәрү барышында гариза һәм мөрәҗәгатьне юллаган, мәгълүмат биргән кешеләрдән өстәмә мәгълүмат һәм материал соратып алу чарасы күрелә, тикшерү объектының Министрлык карамагында булган документлары карала. Башлангыч тикшерү вакытында тикшерү объектыннан алынган мәгълүматка карата аңлатма соралырга мөмкин, әмма андый аңлатма бирү мәҗбүри түгел.

2.21. Башлангыч тикшерү нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрне бозу, бу Регламентның 2.17 пунктының 2 нче ярдәмче пунктында күрсәтелгән фактлар турындагы җитәрлек мәгълүматны алуда кагыйдә бозуга юл куйган затлар ачыкланган очракта, Министрлыкның вәкаләтле заты бу Регламентның 2.17 пунктының 2 нче ярдәмче пунктында күрсәтелгән сәбәпләр буенча планнан тыш тикшерү билгеләү турында нигезле күрсәтмә әзерли.

2.22. Тиешле тикшерү башланганчы аны оештыру өчен сәбәп булган мөрәҗәгать яки гаризаның анонимлыгы яки мөрәҗәгать һәм гаризада дөрес булмаган мәгълүматлар булуы ачыкланган очракта, министр (министр урынбасары) карары буенча башлангыч тикшерү, планнан тыш тикшерү туктатыла.

2.23. Алынган гаризаларда, мөрәҗәгатьләрдә алдан белә торып ялган мәгълүмат күрсәтелгән очракта, Министрлык әлеге гариза, мөрәҗәгатьләрне карау белән бәйле чыгымнарны гражданнардан, шул исәптән тикшерү объектыннан, шәхси эшмәкәрдән түләтү турындагы гариза белән судка мөрәҗәгать итә ала.

2.24. Тикшерү объектына карата планнан тыш тикшерү бу Регламентның 2.17 пунктының 2 нче ярдәмче пунктының “а” һәм “б” ярдәмче пунктларында күрсәтелгән сәбәпләр буенча Министрлык тарафыннан тикшерү объектының эшчәнлек алып бару урыны буенча прокуратура органы белән килештергәннән соң үткәрелә ала.

Дәүләт контролен үткәрүне тормышка ашыручы вазифаи затлар

2.25. Министрлыкның дәүләт контролен башкаруга вәкаләтле вазифаи затлары булып түбәндәгеләр санала:

- министр;
- министр урынбасары;
- Бүлек башлыгы;
- Бүлек белгече.

Дәүләт контролен тормышка ашыру буенча тикшерүләрне түбәндәгеләр башкара ала:

- Бүлек башлыгы;

- Бүлекнең әйдәп баручы киңәшчеләре;
- Бүлекнең әйдәп баручы консультантлары.

Юридик затларга карата № 294-ФЗ Федераль законны бозган өчен җаваплылык

2.26. № 294-ФЗ Федераль законны бозуга юл куйган, тикшерүләр үткәрүгә сәбәпсез каршы килүчеләр һәм (яки) Министрлыкның ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуны бетерү турындагы күрсәтмәсен вакытында үтәмәгән юридик затлар, аларның җитәкчеләре, башка вазифаи затлар яки юридик затларның вәкаләтле вәкилләре Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка ия.

Тикшерү үткәргән вакытта Министрлык, аның вазифаи затларына карата җаваплылыгы

2.27. Министрлык, аның вазифаи затлары тикшерү үткәргән вакытта функцияләрен, хезмәт бурычларын тиешенчә үтәмәгән, хокуксыз гамәлләр кылган вакытта Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка ия.

Россия Федерациясе законнарын бозуда гаепле затларга карата күрелгән чаралар турында, андый чаралар күрелгәч ун көн дәвамында Министрлык законлы хокуклары һәм (яки) мәнфәгатьләре бозылган юридик затка язма формада хәбәр итәргә тиеш.

## 3. ТИКШЕРҮ ОБЪЕКТЫННАН ТАЛӘП ИТЕЛГӘН МӘҖБҮРИ ТАЛӘПЛӘР

3.1. Үтәлеше министрлык тарафыннан контрольдә тотылган мәҗбүри таләпләр, аларны раслаучы норматив хокукый актлар, тикшерү үткәргән вакытта тикшерү объектыннан таләп ителгән документлар исемлеге 1 нче таблицада китерелгән.

1 нче таблица – Тикшерү объектына куелган мәҗбүри таләпләр исемлеге

| Тикшерү объектына куелган мәҗбүри таләпләр исемлеге | Мәҗбүри таләпне раслаучы норматив хокукый акт | Тикшерү объекты тикшерү үткәргән вакытта тәкъдим иткән документлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| **Музей предметлары һәм музей коллекцияләренең сакланышы торышын һәм саклау шартларын тикшерү** | | |
| Музей предметлары һәм музей коллекцияләрен Россия Федерациясе Музей фондына кертү | № 54-ФЗ Федераль законның 6 нчы, 8 нче, 10 нчы маддәләре, | Музей предметларын һәм музей коллекцияләрен Россия Федерациясе Музей фондына кертү турындагы таныклык |

| Тикшерү объектына куелган мәҗбүри таләпләр исемлеге | Мәҗбүри таләпне раслаучы норматив хокукый акт | Тикшерү объекты тикшерү үткәргән вакытта тәкъдим иткән документлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | РФ Хөкүмәтенең 1790 нчы карары; РФ Мәдәният министрлыгының 1319 нчы боерыгы; РФ Мәдәният министрлыгының 1320 нче боерыгы; РФ Мәдәният министрлыгының 470 нче боерыгы. | |
| Музей предметлары һәм музей коллекцияләрен Россия Федерациясе Музей фондыннан чыгару (музей предметын югалту, бозу, шулай ук әлеге музей предметлары һәм музей коллекцияләренә карата үткәрелгән экспертиза белән расланган тарихи-мәдәни, сәнгать, фәнни һәм башка кыйммәте булмауга бәйле) | № 54-ФЗ Федераль законның 9 нчы маддәсе; РФ Хөкүмәтенең 179 нчы карары; РФ Мәдәният министрлыгының 1319 нчы боерыгы; РФ Мәдәният министрлыгының 1320 нче боерыгы. | Музей предметын югалту яки ул җимерелгән очракта: Тикшерү объектының Министрлык адресына әлеге предметлар турындагы мәгълүматта үзгәрешләр булу турындагы мөрәҗәгатьнең күчермәсе: - музей предметлары һәм музей коллекцияләрен Россия Федерациясе Музей фонды составына кертү турындагы таныклык күчермәсе; - үзгәреш кертү өчен сәбәп булырлык документ күчермәсе (предметны югалту турындагы акт (янгын, су басу сәбәпле һ.б.); Эчке эшләр идарәсе, янгын инспекциясе һ.б. органнардан булган вакыйга турындагы акт; югалган предметлар исемлеге; сакланып калган предметларны реставрацияләү мөмкинлеге булмау турында эксперт |

| Тикшерү объектына куелган мәҗбүри таләпләр исемлеге | Мәҗбүри таләпне раслаучы норматив хокукый акт | Тикшерү объекты тикшерү үткәргән вакытта тәкъдим иткән документлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | нәтиҗәсе. |
| Музей предметларын һәм музей коллекцияләрен Татарстан Республикасында Дәүләт музей предметлары һәм музей коллекцияләре каталогына кертү | № 69-ЗРТ ТР Законының 12 нче маддәсе | Музей предметларын һәм музей коллекцияләрен Татарстан Республикасында Дәүләт музей предметлары һәм музей коллекцияләре каталогына кертү фактын раслаучы документ |
| Татарстан Республикасы Дәүләт музей предметлары һәм музей коллекцияләре каталогыннан түбәндәге очракларда чыгарыла:<br>– музей предметлары һәм музей коллекцияләре югалган һәм җимерелгәч<br>· башка музей предметлары һәм музей коллекцияләренә алмаштыргач;<br>– музей предметлары, музей коллекцияләре һәм башка мәдәни мирасның мәдәни-тарихи әһәмияте, физик торышы һәм башка үзенчәлекләре турындагы ялгыш эксперт нәтиҗәсе;<br>– законда каралган башка очракларда. | № 69-ЗРТ ТР Законының 13 нче маддәсе | Музей предметы югалган һәм җимерелгән очракта:<br>Тикшерү объектыннан Министрлык адресына предметлар турындагы мәгълүматта үзгәрешләр хакында мөрәҗәгать күчермәсе, түбәндәге документлар белән:<br>- музей предметларын һәм музей коллекцияләрен Татарстан Республикасында Дәүләт музей предметлары һәм музей коллекцияләре каталогына кертүне раслаучы документ күчермәсе;<br>- үзгәрешләр кертү өчен нигез булырлык документ күчермәсе (предметны югалту турындагы акт (янгын, су басу сәбәпле); Эчке эшләр идарәсе органнары, янгын инспекциясеннән булган вакыйга турындагы акт; югалган предметлар исемлеге; сакланып калган предметларны реставрацияләп булмау турындагы эксперт нәтиҗәсе. |
| Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы яки җирле үзидарә органнары һәм тикшерү объекты арасында Россия | № 54-ФЗ Федераль законның 16 нчы маддәсе; РФ Хөкүмәтенең 179 нчы | Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше составына кергән һәм федераль милектә булган музей предметларын һәм музей коллекцияләрен бушлай бөтенләйгә яки билгеле бер вакытка |

| Тикшерү объектына куелган мәҗбүри таләпләр исемлеге | Мәҗбүри таләпне раслаучы норматив хокукый акт | Тикшерү объекты тикшерү үткәргән вакытта тәкъдим иткән документлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Федерациясе Музей фонды составына керүче музей предметлары һәм музей коллекцияләрен мәдәният өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы рөхсәте белән Татарстан Республикасы карамагында булган юридик затларга яки Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре карамагында булган юридик затларга билгеле бер вакытка файдалануга бирү | карары; РФ Мәдәният министрлыгының 05.05.2009 № 226 боерыгы; РФ Мәдәният министрлыгының 1321 нче боерыгы | файдалануга бирү турындагы килешү |
| Музей предметлары һәм музей коллекцияләренең физик сакланышын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү | № 54-ФЗ Федераль законның 5 нче маддәсе; № 69-ЗРТ ТР Законының 9 нчы маддәсе; РФ Хөкүмәтенең 179 нчы карары | *1. Устав документлары, норматив актлар:*<br>устав (нигезләмә);<br>тикшерелә торган тикшерү объектының дәүләт теркәве турындагы таныклык,<br>*2. Эчке карарлар документлары:*<br><br>оештыру структурасы;<br>штат расписаниесе;<br>структур бүлекчәләр турындагы нигезләмә;<br>Эксперт фонд-сатып алу комиссиясе, Фәнни-методик һәм Реставрация советлары турындагы нигезләмә; музей предметларын һәм музей коллекцияләрен исәпкә алу, саклау һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүне регламентлаучы музей эчендәге инструкцияләр;<br>исәп-саклау эшчәнлеген башкаручы хезмәткәрләрне билгеләү турындагы боерыклар; |

| Тикшерү объектына куелган мәҗбүри таләпләр исемлеге | Мәҗбүри таләпне раслаучы норматив хокукый акт | Тикшерү объекты тикшерү үткәргән вакытта тәкъдим иткән документлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | исәп-саклау эшчәнлеген башкаручы хезмәткәрләрнең вазифаи инструкцияләре;<br>музей предметлары һәм музей коллекцияләренең сакланышы һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен җавап бирүче затларның вазифаи инструкцияләре.<br>*3.Кадрлар:*<br>тикшерү объекты эшчәнлегенең исәп-саклау юнәлешенең кадрлар белән тәэмин ителеше турындагы белешмә;<br>исәп-саклау корпусы кадрлар составының квалификация таләпләренә туры килүе турындагы белешмә.<br>*4.Милек комплексы:*<br>Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан бинага хокукны теркәү турындагы өземтә;<br>җир кишәрлегенә хокукны теркәү турындагы белешмә; саклау статусы (бина тарих һәм мәдәни мирас һәйкәле саналса);<br>саклык вазифасы; һәйкәл паспорты;<br>бинаның гомум торышын бәяләү (тикшерү акты нигезендә);<br>инженерлык һәм коммуникация челтәрләре торышы; тузу проценты; эчке техник хезмәтләрне тикшерү акты.<br>*5.Матди-техник база:*<br>Фонд складларының торышын һәм җиһазланышын техник тикшерү турындагы мәгълүматлар;<br>Экспозиция-күргәзмә җиһазларын техник тикшерү |

| Тикшерү объектына куелган мәҗбүри таләпләр исемлеге | Мәҗбүри таләпне раслаучы норматив хокукый акт | Тикшерү объекты тикшерү үткәргән вакытта тәкъдим иткән документлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | турындагы мәгълүматлар.<br>6. *Музей предметларын саклау һәм экспонатлау режимы:*<br>Температура-дымлылык режимын техник тикшерү турындагы мәгълүматлар;<br>ут режимын техник тикшерү мәгълүматлары;<br>санитар-гигиена режимын техник тикшерү мәгълүматлары.<br>*7. Музей предметларын һәм музей коллекцияләрен исәпкә алу. Тикшерү объекты, шәхси эшмәкәрнең төп һәм ярдәмче исәп документлары:*<br>Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше составына кергән һәм федераль милектә булган музей предметлары һәм музей коллекцияләрен бушлай бөтенләй файдалану яки вакытлы файдалануга тапшыру турындагы килешү;<br>Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше составына кергән һәм Татарстан Республикасы милкендә булган музей предметлары һәм музей коллекцияләрен оператив идарәгә тапшыру турындагы килешү;<br>музей предметлары алыну кенәгәсе;<br>инвентарь кенәгәләр;<br>алыну һәм инвентарь кенәгәләрнең көндәлек исемлеге;<br>теркәү журналлары белән фондларның килү, күчерү һәм хәрәкәт итү актлары;<br>музей предметлары һәм музей коллекцияләре булу-булмауны |

| Тикшерү объектына куелган мәҗбүри таләпләр исемлеге | Мәҗбүри таләпне раслаучы норматив хокукый акт | Тикшерү объекты тикшерү үткәргән вакытта тәкъдим иткән документлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | чагыштыру үкәрүнең план-графигы;<br>музей предметлары һәм музей коллекцияләре булу-булмауны чагыштыру акты;<br>саклаучыларның шәхси эшләре;<br>дәүләт контролен башкару буенча башка документлар.<br>8. *Куркынычсызлык:*<br>ТР буенча Эчке эшләр министрлыгының ведомстводан тыш сак органнары белән сак оештыруга килешү;<br>тикшерү объекты, шәхси эшмәкәрнең куркынычсызлык хезмәтендә эшләүчеләрнең вазифаи инструкцияләре;<br>тикшерү объектына сакны оештыру турында инструкция;<br>пропуск һәм объект эчендәге режимнар турында инструкцияләр;<br>гадәттән тыш хәлләр туган вакытта нарядка эш тәртибе турында инструкцияләр;<br>постларда объектны саклау планы;<br>объектны саклау буенча постларны дислокацияләү;<br>постларны кабул итү-тапшыру һәм хезмәтне тикшерү журналы;<br>постта торучылар алмашкан вакытта бина, милек һәм эш документларын исәпкә алу;<br>пост карточкалары (патрульлек итү яки хәрәкәт маршруты);<br>фондны һәм башка махсус режимлы биналарны ачарга хокуклы кешеләрнең расланган исемлеге, аларның имза үрнәкләре, яшәү урыны адреслары һәм өй |

| Тикшерү объектына куелган мәҗбүри таләпләр исемлеге | Мәҗбүри таләпне раслаучы норматив хокукый акт | Тикшерү объекты тикшерү үткәргән вакытта тәкъдим иткән документлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | телефоннары белән;<br>пломбаларның эзләре, мөһерләрнең үрнәкләре;<br>чын имза, мөһер, шулай ук тәүлек дәвамында пропускның гамәлдә булу вакытын билгели торган шифр-билге белән даими, вакытлы һәм бер тапкыр бирелә торган пропуск үрнәкләре;<br>бер тапкыр бирелә торган һәм материаль пропускларны исәпкә алу журналы;<br>сигнализация чаралары торышын тикшерү һәм аның кабынуын теркәү журналы;<br><br>объектны саклау буенча хезмәт итүне тикшерергә хокуклы затлар исемлеге;<br>объектның эш тәртибе;<br>СПМ (ПЦО), ССПМ, ведомстводан тыш һәм янгын сагы бүлекләре, эчке эшләр бүлекләре, объект җитәкчеләре, медицина ярдәме, авария хезмәте телефоннары исемлеге;<br>пост хезмәткәрләренең эш графигы;<br>сакның техник чараларына хезмәт күрсәтүче һәм ремонтлаучы оешма белән килешү;<br>сакның техник чаралары тузу турындагы акт;<br>Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Дәүләт янгын хезмәте белән килешү;<br>янгын куркынычсызлыгы өчен җаваплы кешеләрне билгеләү турында оештыру-боеру |

| Тикшерү объектына куелган мәҗбүри таләпләр исемлеге | Мәҗбүри таләпне раслаучы норматив хокукый акт | Тикшерү объекты тикшерү үткәргән вакытта тәкъдим иткән документлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | документлары;<br>янгын чыккан очракта кешеләрне, матди һәм мәдәни мирасларны эвакуацияләүнең расланган планы һәм хезмәткәрләрнең гамәли куллануга әзерлеге;<br>мәдәни мирасны урлауны кисәтүгә юнәлдерелгән профилактика чаралары планы.<br>*9. Хисап формалары:*<br><br>“Росстатның № 764 мәдәният оешмалары эшчәнлеген федераль статистик күзәтү боерыгы белән расланган “Музейлар эшчәнлеге турындагы мәгълүматлар” № 8-НК федераль дәүләт статистик күзәтү формасы (алга таба – форма 8-НК)<br>Росстатның 6 нчы карары белән расланган “Музей предметларында кыйммәтле металлар һәм кыйммәтле ташлар булу турындагы мәгълүматлар” федераль дәүләт статистик № 4-экспонатлар күзәтү формасы<br>10. *Тикшерү объектын алдагы тикшерү тәкъдимнәре үтәлеше:*<br>тикшерүләр акты;<br>тикшерү тәкъдимнәрен үтәү турындагы белешмә |
| Музей предметлары һәм музей коллекцияләре белән бәйле исәп документларын алып бару һәм аларның сакланышы | № 54-ФЗ Федераль законның 6 нчы маддәсе; № 69-ЗРТ ТР Законының 9 нчы маддәсе | *Төп исәп документлары:*<br>Төп инвентарь кенәгәсе (килүләр кенәгәсе);<br>фәнни-ярдәмлек фонды килүләр кенәгәсе;<br>вакытлы килүләр кенәгәсе;<br>инвентарь кенәгәләре (коллекцияләр буенча); |

| Тикшерү объектына куелган мәҗбүри таләпләр исемлеге | Мәҗбүри таләпне раслаучы норматив хокукый акт | Тикшерү объекты тикшерү үткәргән вакытта тәкъдим иткән документлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | кыйммәтле металлар һәм кыйммәтле ташлардан ясалган предметларны исәпкә алу өчен махсус инвентарь кенәгәләре;<br>музей предметлары һәм музей коллекцияләрен вакытлы (даими) саклануга кабул итү актлары;<br>музей предметлары һәм музей коллекцияләрен вакытлы файдалануга тапшыру актлары;<br>музей предметлары һәм музей коллекцияләрен күчерү актлары (Россия Федерациясе Музей фонды составыннан чыгарган очракта).<br>*Ярдәмче исәп документлары:*<br>чимал материаллары фонды килүләр кенәгәсе;<br>музей эчендәге кабул итү һәм тапшыру актлары;<br>бөтен төр исәп документларын теркәү журналы;<br>килүләр кенәгәсе һәм инвентарь китапларының еллык описьлары;<br>топографик описьлар;<br>музей предметлары һәм музей коллекцияләренең булу-булмавына чагыштыру үткәрү план-графигы;<br>музей предметлары һәм музей коллекцияләренең булу-булмавына чагыштыру үткәрү актлары. |
| Музей предметлары һәм музей коллекцияләрен фәнни, мәдәни, мәгариф, иҗади максатларда файдалану. | № 54-ФЗ Федераль законның 16 нчы маддәсе;<br>№ 69-ЗРТ ТР Законының 9 нчы маддәсе | Тикшерү объектының тиешле елга эш планы;<br>тиешле елга экспозиция-күргәзмә эшчәнлеге планы;<br>тиешле елга нәшрият эшчәнлеге планы;<br>хисап елына эшчәнлек турындагы хисап |

| Тикшерү объектына куелган мәҗбүри таләпләр исемлеге | Мәҗбүри таләпне раслаучы норматив хокукый акт | Тикшерү объекты тикшерү үткәргән вакытта тәкъдим иткән документлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Тикшерү объектына (Татарстан Республикасы дәүләт музейлары) беркетелгән күчемсез милекне оператив идарә хокукларында тиешенчә файдалану | № 54-ФЗ Федераль законның 29 нчы маддәсе | Җир кишәрлегеннән файдалануга килешү яки акт;<br>кишәрлекнең кадастр буенча номеры;<br>сак статусы (бина тарихи һәм мәдәни һәйкәл саналса);<br>күчемсез милекне арендалау килешүе;<br>тикшерү объектын төрле чыганаклардан финанслау турында белешмә, шул исәптән музей фондлары сакланышына җибәрелгән алдагы финанс елы өчен;<br>тиешле елга чыгымнар һәм керемнәр сметасы;<br>баланс хисаплары күчермәсе;<br>БТИ паспорты (номер/дата);<br>Күчемсез милек объектының федераль милек реестрындагы номеры |
| Россия Федерациясеннән читкә чыгаруга юл куймау максаты белән Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметлары һәм музей коллекцияләре исәбе | № 54-ФЗ Федераль законның 11 нче маддәсе;<br>1993 елның 15 апрелендә кабул ителгән № 4804-1 Федераль закон | Музей предметлары һәм музей коллекцияләрен исәп документлары белән чагыштыру актлары;<br>вакытлы куллануга тапшыру актлары |
| Татарстан Республикасы милкендә булган музей предметлары һәм музей коллекцияләрен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы рөхсәте белән Татарстан Республикасында | № 69-ЗРТ ТР Законының 9 нчы маддәсе | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы рөхсәте;<br>мәдәният өлкәсендә дәүләти җайга салуны башкаруга вәкаләтле федераль мәдәният учреждениесе яки РФ субъекты башкарма хакимияте органына |

| Тикшерү объектына куелган мәҗбүри таләпләр исемлеге | Мәҗбүри таләпне раслаучы норматив хокукый акт | Тикшерү объекты тикшерү үткәргән вакытта тәкъдим иткән документлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| һәм аннан читтә булган башка музейларга һәм оешмаларга күргәзмә һәм башка максатларда вакытлыча бирүне башкару | | музей предметлары һәм музей коллекцияләренә иминият бәясе нигезендә тулы сакланыш һәм куркынычсызлык тәкъдим итү турында гарантия хаты;<br>кызыксынган юридик затларның музей предметлары һәм музей коллекцияләрен экспонатлау шартлары турындагы килешүе (музей предметларына өченче затларның ихтимал дәгъваларыннан һәм чыгымнар күтәрүгә бәйле кирәкле һәм тиешле чаралар кабул итү турындагы пунктларны да кертеп);<br>тикшерү объектлары Фонд-сатып алу комиссиясенең иминият бәяләрен билгеләп вакытлы экспонатлауга тапшырылган музей предметлары исемлеге белән беркетмәсе;<br>һәр музей предметы сакланышы торышы турындагы мәгълүматлар, музей предметларын вакытлы экспонатлауга тапшыру һәм аларны транспортлау ихтималы турындагы нәтиҗә булган тикшерү объекты Реставрация советының беркетмәсе;<br>иминият полисы (музей предметлары һәм музей коллекцияләрен иминиятләштерү, транспортлау, саклау һәм экспонатлау, вакытында кире кайтаруны да кертеп) |
| **Россия Федерациясе Музей фонды дәүләт исәбен алуны башкару өчен кирәкле музей предметлары һәм музей коллекцияләре турындагы мәгълүмат алу өчен сорау җибәрү** | | |

| Тикшерү объектына куелган мәҗбүри таләпләр исемлеге | Мәҗбүри таләпне раслаучы норматив хокукый акт | Тикшерү объекты тикшерү үткәргән вакытта тәкъдим иткән документлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | |
| Тикшерү объекты тарафыннан ел саен эшчәнлеге турындагы мәгълүматны тәкъдим итү | Росстатның 2005 елның 11 июлендә кабул ителгән 43 нче карары | Федераль дәүләт статистик күзәтүнең № 8-НК “Музей эшчәнлеге турындагы мәгълүматлар” формасы |
| Тикшерү объектының ел саен музей предметларында кыйммәтле металлар һәм кыйммәтле ташлар турындагы мәгълүматлар тәкъдим итү | Росстат тарафыннан 2004 елның 23 гыйнварында кабул ителгән 6 нчы карар | Федераль дәүләт статистик күзәтүнең № 4-экспонатлар “Музей предметларында кыйммәтле металлар һәм кыйммәтле ташлар турындагы мәгълүматлар” формасы |

3.2. Тикшерү объекты тарафыннан мәҗбүри таләпләр бозылуны кисәтү, мәҗбүри таләпләр бозылуга мөмкинлек бирүче сәбәпләр, факторлар һәм шартларны бетерү максатында Министрлык ел саен үзләре раслаган кагыйдә бозуларны кисәтү программалары нигезендә мәҗбүри таләпләрне бозуны кисәтү буенча чараларны тормышка ашыра.

3.3. Мәҗбүри таләпләрне бозуны кисәтү максатларында Министрлык № 294-ФЗ Федераль законның 8.2 маддәсенең 5-7 өлешләре белән расланган тәртип нигезендә мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куярга ярамау турында кисәтү бирә һәм тикшерү объектына мәҗбүри таләпләрне үтәүне тәэмин итү буенча чаралар күрүне һәм бу хакта Министрлык тарафыннан расланган вакыт эчендә хәбәр итүне күздә тота.

3.4. Мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турындагы кисәтүне төзү тәртибе һәм җибәрү, тикшерү объекты тарафыннан андый кисәтүгә карата шикаять белдерү һәм аларны карау, андый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

## 4. ТИКШЕРҮ ОБЪЕКТЫ ТИКШЕРҮ ВАКЫТЫНДА ТӘКЪДИМ ИТКӘН ДОКУМЕНТЛАР

Тикшерү объекты тикшерү үткәргән вакытта тәкъдим иткән документлар исемлеге, шулай ук андый документларның формасын раслаучы норматив хокукый актлар 2 нче таблицада китерелгән.

Таблица 2 – Тикшерү объекты тикшерү үткәрүнең максатына һәм бурычларына ирешү өчен тәкъдим иткән документлар исемлеге

| | Тикшерү үткәрү өчен | Документның формасын раслаучы |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| | тәкъдим ителгән документ | норматив хокукый акт |
| | | |
| . | Музей предметлары алыну кенәгәсе | СССР Мәдәният министрлыгы ның 1985 елның 7 июлендә кабул ителгән “СССР дәүләт музейларында булган музей байлыкларын исәпкә алу һәм саклау буенча инструкцияләр”не раслау турында”гы 290 нчы боерык |
| | Инвентарь кенәгәләре | СССР Мәдәният министрлыгының 1985 елның 7 июлендә кабул ителгән “СССР дәүләт музейларында булган музей байлыкларын исәпкә алу һәм саклау буенча инструкцияләр”не раслау турында”гы 290 нчы боерык |
| | Эксперт фонд-сатып алу комиссиясе, Фәнни-методик һәм Реставрация советлары турындагы нигезләмә | СССР Мәдәният министрлыгының 1985 елның 7 июлендә кабул ителгән “СССР дәүләт музейларында булган музей байлыкларын исәпкә алу һәм саклау буенча инструкцияләр”не раслау турында”гы 290 нчы боерык |
| | Исәп-сак эшчәнлеген башкаручы хезмәткәрләрнең вазифаи инструкцияләре | СССР Мәдәният министрлыгының 1985 елның 7 июлендә кабул ителгән “СССР дәүләт музейларында булган музей байлыкларын исәпкә алу һәм саклау буенча инструкцияләр”не раслау турында”гы 290 нчы боерык |
| | Теркәү журналлары белән фондларның килү, күчерү һәм хәрәкәт итү актлары | СССР Мәдәният министрлыгының 1985 елның 7 июлендә кабул ителгән “СССР дәүләт музейларында булган музей байлыкларын исәпкә алу һәм саклау буенча инструкцияләр”не раслау турында”гы 290 нчы боерык |
| | Музей предметлары һәм музей коллекцияләре булу-булмауга чагыштыруның план-графигы һәм акты | СССР Мәдәният министрлыгының 1985 елның 7 июлендә кабул ителгән “СССР дәүләт музейларында булган музей байлыкларын исәпкә алу һәм саклау буенча инструкцияләр”не раслау турында”гы 290 нчы боерык |
| | Федераль дәүләт статистик күзәтүнең № 8-НК “Музей эшчәнлеге турындагы мәгълүматлар” формасы; Федераль дәүләт | Росстатның 2016 елның 7 нче декабрендә кабул ителгән “Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының мәдәният оешмалары эшчәнлеге өчен федераль статистик күзәтүне оештыру өчен |

| | | |
|---|---|---|
| | статистик күзәтүнең № 4-экспонатлар “Музей предметларында кыйммәтле металлар һәм кыйммәтле ташлар турындагы мәгълүматлар” формасы | статистик инструментларны раслау турында”гы 784 нче боерыгы<br>Росстатның 2004 елның 23 гыйнварында кабул ителгән “Россия Финанс министрлыгы карамагындагы Россия Гохран оешмалары өчен музей предметларында кыйммәтле металлар һәм кыйммәтле ташлар булуны статистик күзәтү өчен статистик инструментларны раслау турында”гы 6 нчы карары |

## 5. АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫҢ (ГАМӘЛЛӘР) СОСТАВЫ, ЭЗЛЕКЛЕЛЕГЕ ҺӘМ АЛАРНЫ ҮТӘҮ ВАКЫТЫ, АЛАРНЫ ҮТӘҮ ТӘРТИБЕНӘ ТАЛӘПЛӘР, ШУЛ ИСӘПТӘН ЭЛЕКТРОН ФОРМАДАГЫ АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫ (ГАМӘЛЛӘР) ҮТӘҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

5.1. Дәүләт контроле түбәндәге формада башкарыла:

- музей предметлары һәм музей коллекцияләре сакланышы һәм саклау шартлары торышын тикшерү (планлы, планнан тыш, документар, күчмә тикшерүләр);
- Россия Федерациясе Музей фонды дәүләт исәбен башкару өчен кирәкле музей предметлары һәм музей коллекцияләре турында мәгълүмат алу өчен запрос юллау (алга таба – запрос юллау һәм мәгълүмат алу).

5.2. Бу Регламент түбәндәге процедураларны үтәүне күздә тота:

планлы документар тикшерү үткәрү;

планлы күчмә тикшерү үткәрү;

планнан тыш документар тикшерү үткәрү;

планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү;

запрос юллау һәм мәгълүмат алу.

Планлы һәм планнан тыш тикшерү документар тикшерү һәм (яки) күчмә тикшерү формасына үткәрелә.

Дәүләт функциясен үтәүнең блок-схемасы бу регламентка 4 нче кушымтада китерелә.

Дәүләт функциясен туктатып тору Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда рөхсәт ителә.

### “Планлы документар тикшерү үткәрү” административ процедурасы

5.3. Административ процедура башлау өчен сәбәп булып тикшерү объектын еллык тикшерү планына кертү тора.

5.4. Административ процедура түбәндәге административ гамәлләр тәртибе нигезендә башкарыла:

тикшерү үткәрү өчен җаваплы вазифаи затлар билгеләү;

тикшерү үткәрү турында боерык әзерләү;

тикшерелә торган затка тикшерү үткәрү турында хәбәр итү;

тикшерү үткәрү;

тикшерү нәтиҗәләре буенча тикшерү акты рәсмиләштерү;

ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозу очракларын бетерү буенча чаралар күрү.

5.5. Документар тикшерү (планлысы да, планнан тыш та) Министрлык урнашкан урын буенча үткәрелә.

5.6. Еллык план нигезендә Бүлек башлыгы тикшерү объектын планлы документар тикшерү үткәрү өчен җаваплы вазифаи затлар билгели (алга таба – җаваплы башкаручы).

Тикшерү үткәрү өчен җаваплы вазифаи зат министрның (министр урынбасары) конкрет тикшерү үткәрүгә боерыгы белән раслана.

Үтәү вакыты: планлы документар тикшерү башланырга җиде көн алдан да соңга калмыйча.

Гамәлләрнең нәтиҗәсе: планлы документар тикшерү үткәрү өчен билгеләнгән җаваплы башкаручы.

5.7. Җаваплы башкаручы:

- бу Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән расланган гомум форма буенча планлы документар тикшерү үткәрү турындагы боерык проектын әзерли, аны Бүлек башлыгы белән килештерә;

Планлы документар тикшерү үткәрү турындагы боерык проектын министрга (министр урынбасары) имзаларга җибәрә.

Тикшерү үткәрү турындагы боерыкта түбәндәгеләр күрсәтелә:

Министрлык атамасы, шулай ук дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләре;

Тикшерү үткәрү өчен вәкаләтле вазифаи зат яки вазифаи затлар, шулай ук тикшерү үткәрүгә җәлеп ителгән экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләренең исем-фамилияләре, вазифалары;

тикшерү үткәрелгән тикшерү объектының атамасы, тикшерү объектының урнашкан урыны (аның филиаллары, вәкиллекләре, структур бүлекчәләре);

тикшерүнең максаты, бурычлары, предметы һәм аны үткәрү срогы;

тикшерү үткәрүнең хокукый нигезләре;

тикшерелергә тиешле мәҗбүри таләпләр;

тикшерү үткәрүнең максатына һәм бурычларына ирешү өчен кирәкле контроль буенча чаралар үткәрү вакыты һәм исемлеге;

дәүләт контролен башкару өчен кирәкле административ регламентлар исемлеге;

тикшерү үткәрүнең максаты һәм бурычларына ирешү өчен кирәкле документлар исемлеге;

тикшерү үткәрүнең башлану һәм тәмамлану датасы;

министр (министр урынбасары) боерыгының гомум формасында каралган башка мәгълүматлар.

Тикшерү тикшерү үткәрү турындагы боерыкта күрсәтелгән вазифаи затлар тарафыннан гына үткәрелергә мөмкин.

Тикшерү үткәрү өчен җаваплылар булып министр (министр урынбасары) боерыгы белән конкрет тикшерү үткәрү өчен вәкаләтле вазифаи затлар санала.

Үтәү вакыты: тикшерү үткәрү башланырга биш көннән дә соңга калмыйча.

Гамәлләр нәтиҗәсе: министр (министр урынбасары) тарафыннан имзаланган тикшерү үткәрү турындагы боерык.

5.8. Җаваплы башкаручы тикшерелүче затка министрның (министр урынбасары) планлы тикшерү үткәрүне башлау турындагы боерык күчермәсе белән алу турындагы хәбәр белән заказлы хат һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән кул куелган һәм тикшерү объектының электрон почта адресына электрон документ белән хәбәр итә.

Үтәү вакыты: аны үткәрү башланырга өч көннән дә соңга калмыйча.

Гамәлнең нәтиҗәсе: тикшерелә торган затка тикшерү үткәрү турында хәбәр итү.

5.9. Тикшерелә торган зат хәбәр алынгач ун эш көне дәвамында Министрлыкка боерык күчермәсендә күрсәтелгән документларны җибәрергә тиеш.

Тикшерү үткәрү турындагы боерыкта күрсәтелгән документлар мөһер (ул булган очракта) һәм җитәкче, тикшерү объектының башка вазифаи заты имзасы белән расланган күчермәләр рәвешендә тәкъдим ителә. Тикшерә торган зат запроста күрсәтелгән документларны электрон документлар формасында тәкъдим итәргә хокуклы.

5.10. Әгәр дә Россия Федерациясе законнарында каралмаган булса, Министрлыкка тәкъдим ителгән документларның күчермәләрен нотариуста раслатуны таләп итәргә ярамый.

Документар тикшерү үткәргән вакытта Министрлык тикшерү объектыннан документар тикшерүгә кагылышы булмаган, шулай ук Министрлык башка дәүләт контроле (күзәтүе), муниципаль контроль органнарыннан ала алган мәгълүмат һәм документларны таләп итәргә хокуклы түгел.

Кирәк булган очракта җаваплы башкаручы, шул исәптән электрон формада да, бу Регламентның 2.6 нчы пункты таләпләре нигезендә тиешле тәртиптә документ һәм (яки) мәгълүматны соратып ала.

Документар тикшерү процессында җаваплы башкаручы беренче чиратта тикшерелә торган затның Министрлык карамагында булган документларын тикшерә, шул исәптән алдагы тикшерү актларын, административ хокук бозулар турындагы эшләрне тикшерү материалларын һәм башка документларны.

Җаваплы башкаручы тикшерелүче зат Министрлыкка тәкъдим иткән документларда булган мәгълүмат нигезендә:

- мәгълүматларның дөреслеген бәяли;
- документларда булган мәгълүматны бу Регламентның 3 нче бүлеге нигезендә расланган мәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяли.

Документларда булган мәгълүматлар шик тудырган яки әлеге мәгълүматлар тикшерелә торган затның мәҗбүри таләпләрне үтәвен бәяләргә мөмкинлек бирмәгән очракта җаваплы башкаручы:

- тикшерелүче зат адресына ун эш көне дәвамында документар тикшерү вакытында кирәкле документларны тәкъдим итүне сораган запрос юллый. Запроска министрның (министр урынбасары) документар тикшерү үткәрү турындагы боерык күчермәсе дә тәкъдим ителә.
- нигезле запросны министрга (министр урынбасары) имзалау өчен юллый;
- министр (министр урынбасары) нигезле запроска кул куйганнан соң аны заказлы хат яки башка юл белән аны тикшерә торган затка юллый.

Үтәү вакыты: тикшерү үткәрүгә кадәр биш эш көне дәвамында.

Гамәлнең нәтиҗәсе: тикшерелә торган затның адресына юлланган язма формада аңлатма бирүне таләп иткән нигезле запрос.

Тикшерелә торган зат запроста күрсәтелгән документларның мөһер белән яки тикшерү объектының җитәкчесе яки башка вазифаи зат имзасы балән расланган күчермәсен тәкъдим итә. Тикшерелә торган зат запроста күрсәтелгән документларның электрон вариантын да тәкъдим итәргә хокуклы.

Алда тәкъдим ителгән документларның дөреслеген раслаучы аңлатма һәм (яки) документ алганнан соң, җаваплы башкаручы тикшерелә торган зат тәкъдим иткән алдан бирелгән документларның дөреслген раслый торган аңлатма һәм (яки) документларны карый.

Алдан бирелгән документларның дөреслеген раслаучы аңлатма һәм (яки) документларны караганнан соң яки аңлатмалар булмаган очракта Министрлык гамәлдәге закон таләпләрен бозу билгеләре тапмаса, җаваплы башкаручы күчмә тикшерү үткәрү турында боерык әзерли һәм аны министрга (министр урынбасары) имзаларга җибәрә. Күчмә тикшерү үткәрү турындагы карарны министр (министр урынбасары) кабул итә.

Күчмә тикшерү (аны үткәрү турында карар кабул ителгән очракта) бу Регламентның 5.17 – 5.26 пунктлары нигезендә башкарыла.

Күчмә тикшерү үткәрелгән очракта тикшерү объектыннан документар тикшерү барышында тәкъдим ителгән документлар һәм (яки) мәгълүмат бирүне таләп итү тыела.

Тикшерү объекты законда каралган һәм дәүләт контроле өчен кирәкле мәгълүматны тәкъдим итмәгән һәм Министрлыкка андый мәгълүматларны тулы күләмдә яки вакытында тәкъдим итмәгән очракта РФ Административ хокук бозулар кодексының 19.7 маддәсе буенча административ хокук бозу турында эш кузгатыла.

Үтәү вакыты: аңлатмаларны карау - аңлатма алынганнан соң өч эш көне дәвамында; тикшерү үткәрү – бу Регламентның 2.10 пункты нигезендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: тикшерү объектының документларын һәм (яки) аңлатмасын карау; контроль буенча үткәрелгән тиешле чаралар.

5.11. Тикшерү тәмамлангач җаваплы башкаручы аның нәтиҗәләре буенча тикшерү акты тутыра.

Тикшерү акты бу Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән тиешле форма буенча ике нөсхәдә төзелә.

Тикшерү актына беркетмәләр яки үткәрелгән тикшерү, сынау һәм экспертиза нәтиҗәләре, тикшерү объекты хезмәткәрләре аңлатмалары, ачыкланган кагыйдә бозуларны бетерү турындагы кисәтүләр һәм тикшерү белән бәйле башка документлар яки аларның күчермәләре дә өстәлә.

Контроль буенча чаралар нәтиҗәсендә мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланган очракта җаваплы башкаручы түбәндәгеләрне эшли:

- ачыкланган бөтен кагыйдә бозуларны тикшерү актында терки, аларны раслаучы документларның күчермәләрен китерә;

- Регламентның 5.12 пункты нигезендә ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуны бетерү турында күрсәтмә бирә.

Тикшерү акты ул тәмамланганнан соң ике нөсхәдә тутырыла, аларның берсе кушымта күчермәләре белән тикшерү объектының җитәкчесенә яки вәкаләтле

вәкилгә тикшерү акты белән танышу яки танышудан баш тарту турында расписка белән бергә бирелә.

Тикшерү объектының җитәкчесе, башка вазифаи заты яки вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган зат тикшерү акты белән танышу турында расписка бирүдән баш тарткан вакытта акт алу турындагы хәбәр белән заказлы хат аша җибәрелә, ул Министрлыкта саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә өстәлә. Тикшерелә торган затның дәүләт контроле кысаларында электрон формада хезмәттәшлек итүгә рөхсәте булганда тикшерү акты электрон документ формасында җибәрелә ала.

Тапшыру турындагы хәбәр һәм (яки) актны алуны раслаучы башка дәлил Министрлыкта саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә өстәлә.

Үтәү вакыты:

тикшерү актын төзү һәм тапшыру яки аны тикшерелә торган затка электрон документ рәвешендә җибәрү – контроль буенча чаралар тәмамланганнан соң өч эш көне дәвамында башкарыла, тикшерү акты төзү өчен үткәрелгән тикшерү, сынау, социаль тикшерүләр, экспертиза нәтиҗәләре буенча акт төзү өчен нәтиҗә алырга кирәк булган очракта;

тикшерү акты тикшерелә торган затка заказлы хат белән тикшерү тәмамлангач җибәрелә, әмма акт төзелеп бер эш көненнән дә соңга калмыйча.

Гамәлләрнең нәтиҗәсе: ике нөсхәдә кушымталар белән төзелгән тикшерү акты, аларның берсе тикшерелә торган затка тапшырыла яки юллана, икенчесе эшкә тегеп куела.

5.12.Мәҗбүри таләпләрне бозуга тикшерү үткәргән вакытта җаваплы башкаручы:

- аларны бетерү вакытларын күрсәтеп ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бетерү турында һәм (яки) Россия Федерациясе Музей фонды составына кергән музей предметлары һәм музей коллекцияләренә зыян салуга юл куймау чаралары турындагы күрсәтмәне әзерли һәм тапшыра;

- ачыкланган кагыйдә бозуларны бетерүне контрольдә тоту буенча чаралар күрә, шул исәптән кирәк булган очракта мәҗбүри таләпләрне бозуны бетерү турындагы күрсәтмәне үтәүне планнан тыш тикшерү үткәрә;

- ачыкланган кагыйдә бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрә.

Күрсәтмә тикшерү актына аерылгысыз кушымта санала һәм тикшерү объектының җитәкчесенә, башка вазифаи затка яки вәкаләтле вәкилгә тапшырылырга тиеш, бер үк вакытта аларга бу Регламентның 5.11 пункты нигезендә тикшерү актының да бер нөсхәсе тапшырыла. Актка кул куйгач һәм тапшыргач күрсәтмә әзерләү, рәсмиләштерү һәм тапшыруга юл куелмый.

Җавапы башкаручы күрсәтмәдә аның үтәлү вакытын да күрсәтергә тиеш.

Күрсәтмәдәге барлык таләпләр тулысынча һәм тиешле вакытта үтәлергә тиеш. Күрсәтмә таләпләрен тиешенчә үтәмәү әлеге күрсәтмәне үтәмәү буларак карала.

Күрсәтмәне үтәүне планнан тыш тикшерү бу Регламентның “Планнан тыш документар тикшерү үткәрү” яки “Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү” административ процедураларында расланган тәртиптә үткәрелә.

Мәҗбүри таләпләргә юл куйган затның гамәлләрендә административ кагыйдә бозу билгеләре күренсә, аңа карата административ хокук бозу турындагы эш кузгатыла. Административ хокук бозулар турындагы производство РФ Административ хокук бозулар кодексында каралган тәртиптә башкарыла.

5.13. Тикшерелә торган зат тикшерү актында күрсәтелгән факт, нәтиҗә, тәкъдимнәр яки ачыкланган кагыйдә бозуларны бетерү турындагы күрсәтмә белән килешмәгән очракта, тикшерү акты алынганнан соң унбиш көн дәвамында Министрлыкка язма формада тикшерү актына һәм (яки) ачыкланган кагыйдә бозуларны бетерү күрсәтмәсенә карата шикаять бирә ала. Шул ук вакытта тикшерелә торган зат әлеге шикаятькә аның нигезле булуын дәилләгән документларны да өсти һәм Министрлыкка тапшыра ала. Әлеге документлар тикшерелә торган затның квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә дә җибәрелә ала.

5.14. Тикшерелә торган затның эшчәнегенә карата планлы документар тикшерү үткәрү нәтиҗәләре, шул исәптән ачыкланган кагыйдә бозулар һәм аларны бетерү турындагы күрсәтмәләр аларны бетерү вакытын күрсәтеп Министрлыкның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

Үтәү вакыты: тикшерү тәмамлангач өч эш көне дәвамында.

“Планлы күчмә тикшерү үткәрү” административ процедурасы

5.15. Административ процедура башлау өчен сәбәп булып тикшерү объектын еллык тикшерүләр планына кертү санала, шулай ук документар тикшерү үткәргән вакытта түбәндәгеләрне башкару мөмкин булмаган очракта:

- Министрлык карамагында булган тикшерелә торган затның документларындагы мәгълүматларның тулылыгы һәм дөреслегенә ышанып бумаса;

- контроль буенча тиешле чаралар үткәрмичә тикшерелә торган зат эшчәнлегенең мәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяләп булмаса.

5.16. Административ процедура бу Регламентның 5.4 пунктында китерелгән административ гамәлләр тәртибе нигезендә башкарыла.

5.17. Күчмә тикшерү (планлы да, планнан тыш та) тикшерү объектының урнашкан урыны һәм (яки) аның эшчәнлеге чынлыкта башкарылган урын буенча башкарыла.

5.18. Планлы күчмә тикшерү үткәрү өчен җаваплы башкаручылар билгеләү, боерык проектын әзерләү, тикшерелә торган затка тикшерү үткәрү турындагы хәбәр бу Регламентның 5.6 – 5.8 пунктларында каралган тәртиптә башкарыла.

Тикшерү үткәрү өчен экспертлар, эксперт оешмалары катнашында чаралар үткәрү кирәк булган очракта, тикшерү объекты белән гражданлык-хокукый һәм хезмәти мөнәсәбәтләрдә булмаган экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре чакырыла.

5.19. Җаваплы башкаручы тикшерү объектына килгәч тикшерүне түбәндәгеләрдән башлый:

- Министрлыкның вазифаи заты эш таныклыгын күрсәтә;

- тикшерү объектының җитәкчесен яки башка вазифаи затын, аның вәкаләтле вәкилен түбәндәгеләр белән таныштырудан:

министрның (министр урынбасарының) планлы күчмә тикшерү билгеләү турындагы боерыгы;

күчмә тикшерү үткәрә торган затларның вәкаләтләре;

күчмә тикшерү үткәрүнең максатлары, бурычлары, сәбәпләре;

контроль буенча чараларның төрләре һәм күләмнәре;

күчмә тикшерүгә җәлеп ителгән экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре составы;

аны үткәрү вакыты һәм шартлары;

- тикшерү объектының җитәкчесе яки башка вазифаи затка, вәкаләтле вәкиленә тикшерү үткәрү турындагы боерыкның мөһер белән расланган күчермәсен тапшыру;

үтәү вакыты: тикшерү урынына килеп җитүгә.

Күчмә тикшерү вакытында җаваплы башкаручы түбәндәгеләрне эшли:

- тикшерүнең максаты, бурычлары һәм предметы белән бәйле мәгълүматларны өйрәнә;

- тикшерелә торган затның мәҗбүри таләпләрне үтәвен тикшерә (бу Регламентның 3 нче бүлеге нигезендә);

- кирәк булган очракта тикшерү объектыннан күчмә тикшерүнең максаты, бурычлары һәм предметы белән бәйле документ һәм материалларны соратып ала, күчмә тикшерү алдыннан документар тикшерү үткәрелмәгән очракта мәҗбүри таләпләрне бозган өчен җаваплылык йөкләнгән тикшерү объекты хезмәткәрләренең язма аңлатмаларын ала, тикшерү үткәрү турындагы боерык нигезендә контроль буенча чаралар исемлегендә расланган күләмдә бина, корылма, музей предметлары һәм музей коллекцияләрен тикшерә;

- тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча тәкъдим ителгән документ, материаллар һәм аңлатмаларны анализлый һәм мәҗбүри таләпләрне бозу булу (булмау) турында карар кабул итә;

- тикшерү үткәрү турынагы боерык нигезендә тикшерү объектының мәҗбүри таләпләрне үтәвен бәяләү өчен контроль буенча башка чаралар башкара;

- мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта:

тиешле тәртиптә кагыйдә бозу фактларын раслаучы документларның (алга таба – раслаучы документлар) күчермәләрен әзерли һәм раслата;

тикшерү актына мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары турында мәгълүмат кертә, раслаучы документларның күчермәләрен дә өсти.

Үтәү вакыты: бу Регламентның 2.10 пункты нигезендә.

Гамәлләрнең нәтиҗәсе:

- тикшерү үткәрү турындагы боерык нигезендә контроль буенча чаралар үткәрү;

- мәҗбүри таләпләр булу яки булмауны ачыклау.

5.20. Тикшерү объектының җитәкчесе, вазифаи заты яки вәкаләтле вәкиле таләбе буенча җаваплы башкаручы Министрлык, шулай ук үз вәкаләтләрен раслау максатларында эксперт, эксперт оешмалары турында мәгълүмат бирергә, шулай ук бу Регламент һәм тикшерелә торган зат эшчәнлеген башкарган вакытта файдалана торган объектларда контроль буенча чаралар үткәрү тәртибе белән таныштырырга тиеш.

5.21. Җаваплы башкаручы контроль буенча үткәрелгән чаралар нигезендә бу Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән расланган гомум форма нигезендә ике нөсхәдә тикшерү акты төзи.

Тикшерү акты төзү, ә мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта – ачыкланган кагыйдә бозуларны бетерү турындагы күрсәтмә, тикшерү объектын аңа кушымталар белән таныштыру, тикшерү актын юридик затка тапшыру (юллау) бу Регламентның 5.11 пункты нигезендә башкарыла.

5.22. Җаваплы башкаручы бу Регламентның 1.13 пунктының 2 ярдәмче пункты нигезендә тикшерүләрне исәпкә алу журналына (ул булган очракта) үткәрелгән күчмә тикшерү үткәрү турында яза, анда Министрлык атамасын, тикшерү үткәрү урыны һәм вакытын, хокукый сәбәпләрен, максаты, бурычлары һәм тикшерү предметы, ачыкланган кагыйдә бозулар һәм бирелгән күрсәтмәләр турында өсти, тикшерү үткәргән вазифаи затларның исем-фамилиясен, вазифаларын күрсәтә.

Үтәү вакыты: күчмә тикшерү тәмамланугa.

Тикшерүләрне исәпкә алу журналы булмаган очракта җаваплы башкаручы тикшерүләр актында тиешле язу калдыра.

Тикшерүләрне исәпкә алу журналына тегелгән, номерланган һәм тикшерелә торган затның мөһере белән расланган булырга тиеш (мөһер булган очракта).

5.23. Тикшерелә торган зат тикшерү актында күрсәтелгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр яки планлы күчмә тикшерү вакытында ачыкланган кагыйдә бозуларны бетерү турындагы күрсәтмә белән килешмәгән очракта Министрлыкка бу Регламентның 5.13 пунктында китерелгән таләпләр нигезендә шикаять бирә ала.

5.24. Тикшерү объектының җитәкчесе яки башка вазифаи заты булмау, яки тикшерү объекты тарафыннан эшчәнлек алып барылмау яки тикшерү объектының җитәкчесе яки башка вазифаи затының башка гамәлләре аркасында планлы яки планнан тыш күчмә тикшерү үткәреп булмаса, Министрлыкның вазифаи заты сәбәпләрен күрсәтеп тикшерү үткәреп булмау турында акт төзи.

Җаваплы башкаручы РФ Административ хокук бозулар кодексы таләпләре нигезендә, РФ Административ хокук бозулар кодексының 19.4.1 маддәсендә каралган Министрлыкның вазифаи затының законлы эшчәнлегенә каршы килү турында беркетмә төзүне тәэмин итә.

Үткәрелми калган тикшерүләр турындагы мәгълүмат тиешле тәртиптә прокуратура органнарына җиткерелә.

5.25. Ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү буенча чаралар кабул итү бу Регламентның 5.12 пункты нгезендә башкарыла.

5.26. Тикшерелә торган затның эшчәнлегенә карата планлы күчмә тикшерү үткәрү нәтиҗәләре, шул исәптән ачыкланган кагыйдә бозулар һәм аларны бетерү турындагы күрсәтмәләр аларны бетерү вакытын күрсәтеп Министрлыкның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

Үтәү вакыты: тикшерү тәмамлангач өч эш көне дәвамында.

«Планнан тыш документар тикшерү үткәрү» административ процедурасы

5.27. Планнан тыш документар тикшерүгә бу Регламентның 2.17 пунктында каралган очраклар сәбәп булып тора.

Планнан тыш тикшерү үткәрү сәбәбе булып тикшерелә торган затның ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуны бетерү турындагы күрсәтмәне үтәү вакыты чыгу саналса, бары Министрлык биргән күрсәтмәне үтәү генә андый тикшерү предметы була ала.

5.28.

Административ процедура административ гамәлләрнең түбәндәге тәртибе нигезендә башкарыла:

тикшерү үткәрү өчен җаваплы вазифаи затлар билгеләү;

тикшерү үткәрү турындагы боерыкны әзерләү;

тикшерү үткәрү; тикшерү нәтиҗәләре буенча тикшерү актын төзү;

ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуны бетерү буенча чаралар кабул итү.

5.29. Бу Регламентның 2.17 пунктының 2 һәм 3 ярдәмче пунктларында күрсәтелгән очраклар туган очракта, министр (министр урынбасары) Бүлек башлыгына күчмә тикшерү үткәрү турында йөкләмә бирә. Бүлек башлыгы җаваплы башкаручыны билгели.

Планнан тыш тикшерү үткәрү сәбәбе булып тикшерү объекты тарафыннан ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бетерү буенча күрсәтмәне үтәү вакыты чыгу саналса (бу Регаментның 2.17 пунктының 1 ярдәмче пункты), җаваплы башкаручы булып күрсәтмәне биргән җаваплы башкаручы булачак.

Үтәү вакыты: планнан тыш үткәрү турында йөкләмә кабул ителгән көндә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: билгеләнгән җаваплы башкаручы.

5.30. Җаваплы башкаручы:

- бу Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән расланган гомум форма буенча планнан тыш документар тикшерү үткәрү турында боерык проектын әзерли, анда бу Регламентның 5.7 пунктында китерелгән мәгълүматны күрсәтә, аны Бүлек башлыгы белән килештерә;

- планнан тыш документар тикшерү үткәрү турындагы боерык проектын имзалау өчен министрга (министр урынбасары) җибәрә.

Тикшерүне аны үткәрү турындагы боерыкта күрсәтелгән вазифаи затлар гына үткәрә ала.

Үтәү вакыты: планнан тыш документар тикшерү үткәрү турындагы йөкләмә кабул ителгәч, әмма тикшерү үткәрү турындагы карар кабул ителеп, җаваплы башкаручы билгеләнгәннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча.

Гамәлнең нәтиҗәсе: тикшерү үткәрү турындагы министр (министр урынбасары) имзалаган боерык.

5.31. Планнан тыш документар тикшерү үткәргән вакытта контроль буенча чараларны тормышка ашыру, шул исәптән тикшерү объекты документларында булган мәгълүматларны бәяләү, кирәк булган очракта җаваплы башкаручы бу Регламентның 5.10 пунктында расланган тәртиптә хат юллый, сорау буенча тәкъдим ителгән документлар, материаллар һәм аңлатмалар буенча анализ үткәрелә.

5.32. Тикшерү нәтиҗәләре буенча тикшерү акты рәсмиләштерү, ә мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланган очракта – аларны бетерү турындагы күрсәтмә, тикшерү объектын тикшерү акты һәм аңа кушымталар белән таныштыру, тикшерү объектына актны тапшыру һәм юллау бу Регламентның 5.11 пункты нигезендә башкарыла.

5.33. Ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуны бетерү буенча чаралар кабул итү бу Регламентның 5.12 пункты нигезендә башкарыла.

5.34. Тикшерелә торган зат тикшерү актында күрсәтелгән факт, нәтиҗә, тәкъдимнәр яки ачыкланган кагыйдә бозуларны бетерү турындагы күрсәтмә белән килешмәгән очракта, тикшерү акты алынганнан соң унбиш көн дәвамында Министрлыкка язма формада тикшерү актына һәм (яки) ачыкланган кагыйдә бозуларны бетерү күрсәтмәсенә карата шикаять бирә ала.

5.35. Тикшерелә торган затның эшчәнегенә карата планнан тыш документар тикшерү үткәрү нәтиҗәләре, шул исәптән ачыкланган кагыйдә бозулар һәм аларны бетерү турындагы күрсәтмәләр аларны бетерү вакытын күрсәтеп Министрлыкның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

Үтәү вакыты: тикшерү тәмамлангач өч эш көне дәвамында.

«Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү» административ процедурасы

5.36. Планнан тыш күчмә тикшерү өчен бу Регламентның 2.17 пунктында каралган очраклар нигез булып тора.

5.37. Административ процедура түбәндәге административ гамәлләр тәртибендә башкарыла:

тикшерү үткәрү өчен җаваплы вазифаи затларны билгеләү;

тикшерү үткәрү турындагы боерыкны рәсмиләштерү;

тикшерелә торган затка тикшерү турында хәбәр юллау;

тикшерү үткәрү;

тикшерү нәтиҗәләре буенча тикшерү акты рәсмиләштерү;

ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бетерү буенча чаралар кабул итү.

5.38. Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү өчен җаваплы башкаручылар билгеләү, боерык проектын әзерләү бу Регламентның 5.29, 5.30 пунктында каралган тәртиптә башкарыла.

5.39. Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен бу Регламентның 2.17 пунктының 2 ярдәмче пунктының “а” һәм “б” ярдәмче пунктларында күрсәтелгән сәбәп нигез булып торса, җаваплы башкаручы түбәндәгеләрне эшли:

- тикшерү объектының эшчәнлек башкару урыны буенча урнашкан прокуратура органы белән планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килештерү буенча гариза әзерли (алга таба – тикшерүне прокуратура органы белән килештерү турындагы гариза);

- прокуратура органы белән тикшерүне килештерү турындагы гаризаны министрга (министр урынбасары) имзаларга юллый;

- прокуратура органы белән тикшерүне килештерү турындагы гаризага министр (министр урынбасары) кул куйгач, аны тикшерү объектының эшчәнлек башкару урыны буенча прокуратура органына тапшыру турындагы хәбәр белән заказлы хат

яки электрон имзалы электрон документ юллый. Гаризага министрның (министр урынбасары) тикшерү үткәрү турындагы боерыгының күчермәсе һәм аны үткәрү турында нигез булып хезмәт иткән мәгълүматлар булган документлар да өстәлә.

